| ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ШӘҺӘР СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

08 ноябрь, 2018 ел № 27/8

Шәһәр Советының 2014 елның 09 декабрендәге 35/8 санлы Карары белән расланган товарлар, эшләр, хезмәтләр күрсәтүне сатып алуны формалаштыру, үтәү һәм гамәлгә ашыруны контрольдә тоту тәртибе турында Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү хакында

2013 елның 05 апрелендәге «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр күрсәтүне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 44-ФЗ санлы Федераль закон, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 28 маддәсе 2 өлеше һәм 69 маддәсе нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2014 елның 09 декабрендәге 35/8 санлы Карары белән расланган тварлар, эшләр, хезмәтләр күрсәтүне сатып алуны формалаштыру, үтәү һәм гамәлгә ашыруны контрольдә тоту тәртибе турында Нигезнамәгә (Шәһәр Советының 2015 елның 15 апрелендәге 39/9, 2016 елның 24 февралендәге 6/7 санлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 3 пунктта:

– 2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә :

«2) заказ бирүче – муниципаль заказ бирүче яйсә Федераль законның 15 маддәсе 1 һәм 2.1 өлешләренә нигезләнеп сатып алуларны гамәлгә ашыручы бюджет учреждениесе, муниципаль унитар предприятие.»;

– 7 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасы (алга таба – бердәм мәгълүмат системасы) – Федераль законның 4 маддәсе 3

өлешендә күрсәтелгән һәм мәгълүматлар базаларында, мәгълүмат технологияләре һәм мондый мәгълүматны формалаштыруны, эшкәртүне, саклауны тәэмин итә торган техник чаралар базаларындагы мәгълүмат җыелмасы, шулай ук аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге бердәм мәгълүмат системасының рәсми сайтыннан zakupki.gov.ru бирү;»;

2) 16 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16. План-график заказчы тарафыннан сатып алулар планына үзгәрешләр кертелгән очракта, шулай ук түбәндәге очракларда үзгәртелергә тиеш:

1) контрактның башлангыч (максималь) бәясен, бердәнбер тәэмин итүче (подрядчы, башкаручы) белән төзелә торган контракт бәясен арттыру яки киметү;

2) сатып алу башланганчы контракт срогы, аванс түләү тәртибе яки күләме үзгәрү;

3) сатып алуларны башлау датасы һәм (яки) тәэмин итүчене (подрядчыны, башкаручыны) билгеләү ысулы үзгәрү, заказчы тарафыннан план-графикта каралган сатып алуларны гамәлдән чыгару;

4) Федераль законның 20 маддәсе нигезендә сатып алулар буенча мәҗбүри иҗтимагый фикер алышу нәтиҗәләре белән заказчы тарафыннан кабул ителгән һәм сатып алулар планына үзгәрешләр кертүне таләп итмәүче карарны гамәлгә ашыру;

5) башка очракларда, Федераль законның 21 маддәсе 4 һәм 5 өлешләрендә билгеләнгән план-графикларны формалаштыру, раслау һәм алып бару тәртибе нигезендә;

Сатып алуның һәр объекты буенча план-графикка үзгәрешләр кертү тиешле сатып алуны гамәлгә ашыру турында хәбәрне бердәм мәгълүмат системасында урнаштырганчы яисә тәэмин итүчене (подрядчы, башкаручыны) ябык ысул белән билгеләүдә катнашырга чакыру җибәргәнче ун көн эчендә башкарыла, Федераль законның 55 маддәсе 2,4-6 өлешләре, 55.1 маддәсе 4 өлеше, 71 маддәсе 4 өлеше, 79 маддәсе 4 өлеше, 82.6 маддәсе 2 өлеше, 83 маддәсе 19 өлеше, 83.1 маддәсе 27 өлеше һәм 93 маддәсенә нигезләнеп башкарылучы сатып алулырдан тыш (алар буенча план-графикка үзгәрешләр кертү сатып алуны гамәлгә ашыру турында хәбәрне бердәм мәгълүмат системасында урнаштырганчы яисә ябык ысул белән тәэмин итүче (подрядчы, башкаручы) билгеләүгә чакыру җибәргәнгә кадәр бер көннән дә соңга калмыйча башкарыла, әмма Федераль законның 21 маддәсе 15 олешендә каралган тәртиптә бәрдәм мәгълүмат системасына үзгәрешләр кerткәнгә кадәр түгел).».

2. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев